**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 9 июль № 501

г. Казань

«Казан сәләтлеләр ачык университеты 2.0» автоном коммерциячел булмаган оешмасына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү кагыйдәләрен раслау турында

Татарстан Республикасы Министлар Кабинетының «2015 – 2020 елларга Татарстан Республикасында талантлар белән стратегик идарә итү» дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 3 декабрь, 943 нче карары белән расланган «2015 – 2020 елларга Татарстан Республикасында талантлар белән стратегик идарә итү» дәүләт программасы чараларын гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән «Казан сәләтлеләр ачык университеты 2.0» автоном коммерциячел булмаган оешмасына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү кагыйдәләрен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\501.doc

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 9 июль, 501 нче карары
белән расланды

«Казан сәләтлеләр ачык университеты 2.0» автоном коммерциячел булмаган оешмасына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү кагыйдәләре

1. Әлеге Кагыйдәләр Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә эшләнде һәм «Казан сәләтлеләр ачык университеты 2.0» автоном коммерциячел булмаган оешмасына (алга таба – «КСАУ 2.0» АКО) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү механизмнарын билгели.

2. Субсидия Татарстан Республикасы Министлар Кабинетының «2015 – 2020 елларга Татарстан Республикасында талантлар белән стратегик идарә итү» дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 3 декабрь, 943 нче карары белән расланган «2015 – 2020 елларга Татарстан Республикасында талантлар белән стратегик идарә итү» дәүләт программасы (алга таба – дәүләт программасы) чараларын гамәлгә ашыру максатларында бирелә.

3. Субсидия бирү дәүләт программасы чараларын гамәлгә ашыруга тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында каралган бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә тормышка ашырыла.

4. Субсидияне алу өчен «КСАУ 2.0» АКО Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына (алга таба – Вәкаләтле орган) түбәндәге документларны тапшыра:

әлеге Кагыйдәләргә теркәлгән кушымта нигезендәге форма буенча субсидия бирү турындагы гаризаны;

гаризаны имзалаган затның «КСАУ 2.0» АКО субсидияләр бирүгә вәкаләтләрен раслаучы документны;

«КСАУ 2.0» АКО гамәлгә кую документларының күчермәләрен;

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрына теркәү турындагы шаһәдәтнамә күчермәсен;

«КСАУ 2.0» АКО финанс-хуҗалык эшчәнлеге планының күчермәсен.

5. Вәкаләтле орган әлеге Кагыйдәләрнең 4 нче пунктында күрсәтелгән документларны кабул итү һәм карап тикшерүне гамәлгә ашыра.

6. Субсидия бирү Вәкаләтле орган һәм «КСАУ 2.0» АКО арасында төзелгән субсидия бирү турындагы килешү (алга таба – килешү) нигезендә гамәлгә ашырыла.

Килешү әлеге Кагыйдәләрнең 4 нче пунктында күрсәтелгән документларны Вәкаләтле органга тапшырган көннән соң 15 көн эчендә Вәкаләтле орган тарафыннан расланган форма буенча төзелә.

Килешүдә субсидиянең күләме, максатчан билгеләнеше, аннан файдалану

турындагы хисапны тапшыру тәртибе һәм вакытлары, субсидия алучының субсидиянең хисап финанс елында тотылмый калган өлешен агымдагы финанс елында кайтару очраклары, Вәкаләтле орган, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан «КСАУ 2.0» автоном коммерциячел булмаган оешмасының субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен саклавын, «КСАУ 2.0» АКО әлеге Кагыйдәләрнең шартларын саклау турында нигезләмәне тикшерүләр үткәрүгә «КСАУ 2.0» АКО ризалыгы күздә тотыла.

7. Вәкаләтле орган килешүне төзегән көннән соң 10 көн эчендә «КСАУ 2.0» АКО исәп-хисап счетына субсидияне күчерә.

8. «КСАУ 2.0» АКО Вәкаләтле органга килешү белән күздә тотылган формада һәм тәртиптә субсидиядән файдалану турында хисап тапшыра.

9. Әлеге Кагыйдәләр белән билгеләнгән субсидияләрне бирү максатларын һәм шартларын бозу фактлары билгеле булган, субсидияләрдән максатчан билгеләнештә файдаланмаган, субсидия алу өчен дөреслеккә туры килмәгән белешмәләр һәм документлар тапшырган, субсидиядән файдалану турында хисап тапшырмаган очракта, бирелгән субсидияләр Вәкаләтле органның тиешле таләбен алган көннән соң 30 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кайтарылырга тиеш.

10. Субсидияләр бирү турындагы килешү белән күздә тотылган очракларда, субсидияләрнең хисап финанс елында тотылмый калган өлеше «КСАУ 2.0» АКО тарафыннан хисап елыннан соң киләторган елның 1 февраленә кадәр Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кайтарылырга тиеш.

11. Субсидияләрне кайтару вакытын бозган очракта, Вәкаләтле орган, әлеге Кагыйдәләрнең 9, 10 нчы пунктларында билгеләнгән вакыт чыккан көннән башлап, эш көннәрендә исәпләнә торган 7 көн эчендә, күрсәтелгән акчаны Татарстан Республикасы бюджетына Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән тәртиптә кире кайтару буенча чаралар кабул итә.

12. Вәкаләтле орган һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен саклауны тикшерүне законнар белән билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашыра.

13. Субсидиянең максатчан һәм нәтиҗәле кулланылышын тикшерүдә тоту Вәкаләтле орган тарафыннан законнар нигезендә гамәлгә ашырыла

F:\KARAR\2015\501.doc

«Казан сәләтлеләр ачык университеты 2.0» автоном коммерциячел булмаган оешмасына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү кагыйдәләренә кушымта

Форма

Татарстан Республикасы
Премьер-министры урынбасарына –
Татарстан Республикасы мәгариф
һәм фән министрына
______________________ (Ф.И.А.и.)

«Казан сәләтлеләр ачык университеты 2.0»
автоном коммерциячел булмаган оешмасына
Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирүгә
гариза

_____________________________________ *(юридик затның ИНН)*
_____________________________________ *(юридик затның урнашкан урыны)*

Татарстан Республикасы Министлар Кабинетының «2015 – 2020 елларга Татарстан Республикасында талантлар белән стратегик идарә итү» дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 3 декабрь, 943 нче карарын, шулай ук Татарстан Республикасы Министлар Кабинетының ««Казан сәләтлеләр ачык университеты 2.0» автоном коммерциячел булмаган оешмасына Татарстан Республикасы бюджетынннан субсидияләр бирү турында» 2015 ел, ___________, _____ карарын гамәлгә ашыру максатларында, «Казан сәләтлеләр ачык университеты 2.0» автоном коммерциячел булмаган оешмасына «2015 – 2020 елларга Татарстан Республикасында талантлар белән стратегик идарә итү» дәүләт программасы чараларын гамәлгә ашыру өчен субсидия бирүне сорыйбыз

Түбәндәге форма буенча юридик зат вәкиле турында мәгълүматлар:

| Оешма җитәкчесенең фамилиясе, исеме, әтисенең исеме | Элемтә өчен телефоны, факсы, e-mail |
|---|---|
| | |

Кушымталар: Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, _______________, _________ карары белән расланган «Казан сәләтлеләр ачык университеты 2.0» автоном коммерциячел булмаган оешмасына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү кагыйдәләренең 4 нче пункты нигезендә.

| | |
|---|---|
| Гаризаны тапшыру көне | |
| Юридик затның җитәкчесе имзасы | |
| Мөһер урыны | |